ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

**16 августа 2016 г.** Зеленодольск ш. **№ 03-795**

“Зеленодольск шәһәренең күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләрен иң яхшы бизәү" конкурсын үткәрү турында

«Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең төзеклеген үстерү, киң даирә җәмәгатьчелекне һәм халыкны шәһәрне комплекслы төзекләндерү һәм яшелләндерү эшләренә җәлеп итү, тышкы төзекләндерү объектларына сакчыл караш пропагандалау, «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнар яшәү өчен уңай шартлар тудыру максатларында:

1. «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә 23.08.2016 – 26.08.2016 елларда «Зеленодольск шәһәре күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләрен иң яхшы бизәү» конкурсын (алга таба-Конкурс) үткәрергә.
2. «Иң яхшы ишегалды» (1 нче кушымта) иң төзекләндерелгән шәхси ишегалдына бәйге турындагы нигезләмәне расларга.
3. Конкурс комиссиясенең кушымта составын расларга (2 нче кушымта).
4. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге башлыгына әлеге боерыкны «Зеленодольская правда», «Зеленодольск» газеталарында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) интернетта урнаштырыруны тәкъдим итәргә.
5. Әлеге Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкче А.Х. Сахибуллин

2016 елның 16 августы, № 03-795
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты боерыгына 1 нче кушымта

# Зеленодольск шәһәренең күпфатирлы йортлары "Ишегалды территорияләрен иң яхшы бизәү" конкурсы турында НИГЕЗЛӘМӘ

«Зеленодольск шәһәрендәге күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләрен иң яхшы бизәү» конкурсының әлеге нигезләмәсе (алга таба – нигезләмә) «Зеленодольск шәһәрендәге күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләрен иң яхшы бизәү» конкурсын үткәрү тәртибен һәм шартларын билгели (алга таба – Конкурс).

## 1. Конкурсның максаты

Конкурс Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең төзеклеген үстерү һәм яхшырту, киң даирә җәмәгатьчелекне һәм халыкны шәһәрне комплекслы төзекләндерү һәм яшелләндерү эшләренә җәлеп итү, тышкы төзекләндерү объектларына сак караш пропагандалау, гражданнар өчен «Зеленодольск шәһәре»муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү өчен уңай шартлар тудыру максатында үткәрелә.

## 2. Төп бурычлар

«Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең күпфатирлы йортларында яшәүчеләрне йорт яны территорияләрен, төзекләндерү объектларын карап тоту, төзекләндерү һәм яшелләндерү дәрәҗәсен күтәрү эшчәнлегенә җәлеп итү.

## 3. Конкурста катнашучылар

Катнашуга «Зеленодольск шәһәре»муниципаль берәмлегенең күпфатирлы йортларында яшәүчеләр чакырыла.

Күпфатирлы йортлар советы рәисләреннән гаризалар кабул ителә.

## 4. Конкурсны оештыручы

Конкурсны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты оештыра.

## 5. Конкурсны оештыру һәм үткәрү тәртибе

Конкурс 2016 елның 23 августыннан 2016 елның 26 августына кадәр үткәрелә.

Конкурста катнашу өчен гаризалар 2016 елның 19 августына кадәр Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетында ирекле формада түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Зеленодольск шәһәре, Ленин урамы, 41а йорт.

Конкурста җиңүчеләр комиссия тарафыннан билгеләнә (2 нче кушымта).

Конкурска нәтиҗәләр 2016 елның 29 августында ясалачак.

Конкурста җиңүчеләр грамоталар белән бүләкләнә.

Конкурс йомгаклары буенча кызыксындыру призлары тапшыру тантаналы шартларда 2016 елның 30 августында Зеленодольск шәһәре көнендә үткәрелә.

2016 елның 16 августы, № 03-795
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты боерыгына 2 нче кушымта

**Конкурс комиссиясе**
**Составы**

| | |
|---|---|
| Сахибуллин А.Х. | Зеленодольск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе |
| Герасимов Ю.Н. | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының баш архитекторы, комиссия рәисе урынбасары |
| Халилова Л.Ш. | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, комиссия секретаре |

**Комиссия әгъзалары**

| | |
|---|---|
| Котельников Р.О. | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары |
| Сергеев П.Н. | МБУ "Зеленодольск муниципаль районы архитектура һәм шәһәр төзелеше сәясәте идарәсе" җитәкчесе |
| Бечин Д.А. | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният идарәсе башлыгы |
| Анисимов О.В. | МБУ “Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы торак-коммуналь хуҗалык департаменты " җитәкчесе |